МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

4.05.2023 ел. № 108

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 22 июнендәге 194 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2016 елның 22 июнендәге 194 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 18 апрелендәге 234 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктындагы «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләре белән алмаштырырга;

19 пунктта «кызыксынган оешмалар» сүзләреннән соң «, коррупциягә каршы тору өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасы кулланылырга мөмкин, шул исәптән гаризалар юллау өчен дә» сүзләрен өстәргә.

Министр Ф.М. Хәнифов